**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының**
**Югары Налим авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**18.03.2026 ел** **№ 16**

**Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге Советы 2014 елның 17 ноябрендәге 139 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зәй муниципаль районының Югары Налим авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районының Югары Налим авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге Советы 2014 елның 17 ноябрендәге 139 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына (2015 нче елның 11 сентябрендә № 178, 2018 нче елның 26 октябрендә № 115, 2019 нчы елның 21 мартында № 127, 2019 нчы елның 08 ноябрендә № 153, 2020 нчы елның 11 августында № 174) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктның 4 пунктчасының 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«һәрберсенең кадастр бәясе 300 миллион сумнан арткан салым салу объектлары, төзелеше тәмамланмаган объектларны, күпфатирлы йорт булып торырга тиешле объектларны исәпкә алмыйча;».

2. Карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә, авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Совет рәисе,**
**Югары Налим авыл җирлеге**
**башлыгы** **Г.З.Батькова**